Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге Советы карары

2021 елның 14 июле №25

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында»

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге территориясендә җирләрне оптималь куллану һәм артык вакլануны булдырмау, гражданнарны җир кишәрлекләре белән тәэмин итү һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкны үстерү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексына, Татарстан Республикасы Җир кодексына, «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерль Федераль законга таянып, шулай ук Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 30 статьяның 5, 6 пунктларында, 8 бүлегендә «утыз көн дәвамында» сүзләрен «егерме биш көн дәвамында» сүзләренә алмаштырырга
2. 35.1 статья «Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары» сүзләреннән түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Яңа төзелә торган җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

«индивидуаль торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең минималь күләме - 1 000 кв.м., кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү юлы белән, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару яисә индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләре төзелүдән тыш, аларның мәйданы 1000 кв.м дан да кимрәк булган җир кишәрлеге барлыкка килә;

«индивидуаль торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән куллану рәвешендәге җир кишәрлекләренең максималь күләме - 1 500 кв.м.».

Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән гражданнарга арендага яисә милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) күләмнәрен билгеләргә:

а) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен:

- торак пункт чикләрендә (йорт янындагы җир кишәрлеге) - 0,1 гектардан 0,15 гектарга кадәр,

- торак пункттан читтә (кыр җир кишәрлеге) - 0,1 гектардан 1,0 гектарга кадәр;

б) индивидуаль торак төзелеше өчен 0,1 гектардан 0,15 гектарга кадәр.

3. Әлеге карарның 2 пунктында каралган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) үлчәмнәре гражданнарга әлеге карарның үз көченә рәсми кергәннән соң бирелә торган җир кишәрлекләренә (яңа бүлеп бирелә торган җир кишәрлекләренә) кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның 2 пунктында каралган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) үлчәмнәре гражданнарга әлеге карарны кабул иткәнче аренда хокукларында бирелгән һәм алар тарафыннан гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә милеккә алына торган җир кишәрлекләренә кагылмый дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Балтач ав., Мәктәп ур., 1 йорт (администрация бинасы)
- ТР, Кама Тамагы районы, Балтач авылы, Мәктәп урамы, 2 йорт (Мәдәният йорты бинасы), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге башлыгы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге Советы рәисе Д.И. Мөхәмәдуллин